ГЛАВА ДРОЖЖАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЧҮПРӘЛЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

23.06.2020 с.Старое Дрожжаное № 24

Чүпрәле муниципаль районы башлыгы каршындагы инвестицион климатны яхшырту буенча Иҗтимагый совет турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башлыгының 31.01.2014 ел № 8 карары белән расланган Чүпрәле муниципаль районы башлыгы каршындагы инвестицион климатны яхшырту буенча Иҗтимагый совет турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4.6 пунктны түбәндәге эчтәлекле 4.6.1 пунктчасы белән өстәргә:

«4.6.1. Үз эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен Комиссия әгъзалары хокуклы:

- карала торган мәсьәләнең асылын ачыклау өчен кирәкле булган мәгълүматны, белешмәләрне соратып алырга, документларны (күчермәләрен) соратып алырга);

- аерым фикерен белдерергә һәм аны Совет утырышы беркетмәсенә кертү өчен язма рәвештә бәян бирергә;

- комиссия карарларын үтәүне контрольдә тоту.»;

4.8 пунктны «аны үткәрү датасыннан соң 5 көннән дә соңга калмыйча» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге мәгълүматны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы сайтында Интернет челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Чүпрәле муниципаль районы Башлыгы М. Р. Гафаров